РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМАНАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ» АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«УРМАНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ул. Татарстан д.15«а», с.Урманаево,
Азнакаевский район, 423311

Татарстан урамы, йорт 15 “а”, Урманай авылы
Азнакай районы, 423311

Тел./факс(8-85592)4-30-49/4-31-56; E-mail Azn.Urman@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 08 » ноябрь 2021ел № 06

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май бистәсе торак пунктында теркәлгән Верхняя урамы буенча 01 йорттан 33 йортка кадәр, Нижняя урамы буенча 01 йорттан 16 йортка кадәр теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2023 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2022 елның 23 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май бистәсе торак пунктында теркәлгән Средняя урамы буенча 01 йорттан 12 йортка кадәр, Нижняя урамы буенча 17 йорттан 35 йортка кадәр теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2023 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2022 елның 23 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май бистәсе торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитеты;

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2023 елда Урманай авыл җирлеге Беренче Май бистәсе торак пункты территориясендә Беренче Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне " бәйрәм чараларын үткәрү хезмәтләре күрсәтү»);

- Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, су чыганакларын санитар саклау зоналарын төзекләндерү, ЗСО проектларын әзерләү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, эчә торган суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү);

- Беренче Май бистәсе территориясен төзекләндерүне оештыру (территорияне кипкән агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырылган чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, трактористка механикалаштырылган кар чистарту буенча хезмәт өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен шартнамә буенча эшләр өчен түләү, МТЗ-82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары һәм запчастьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту хезмәте күрсәтү).

**«РИЗА» «КАРШЫ».**

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

6. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: Э.Р.Абдуллина